# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

14.03.2016 № 22

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 13 мартындагы җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә 2016 елның 13 мартында узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде:

"2016 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | мотопомпалар сатып алу:<br>- Иске Чүриле, Венета<br>- Иске Чүриле авылында янгын гидранты урнаштыру | <br>20 000<br>10 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Иске Чүриле авылы<br>Ашабаш авылы<br>Михайловка п. | <br>60 000<br>20 000<br>100 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - чишмә территориясен төзекләндерү;<br>Штерә авылы | 10 000 |
| | | Барлыгы: | 220000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга?"

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1129 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-878, бу 77,77 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 844 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 96,13 % тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 34 кеше тавыш бирде, бу 3,87 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныырга.

2. “2016 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | мотопомпалар сатып алу:<br>- Иске Чүриле, Венета<br>- Иске Чүриле авылында янгын гидранты урнаштыру | <br>20 000<br>10 000 |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу:<br>Иске Чүриле авылы<br>Ашабаш авылы<br>Михайловка п. | <br>60 000<br>20 000<br>100 000 |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | - чишмә территориясен төзекләндерү;<br>Штерә авылы | 10 000 |
| | | Барлыгы: | 220000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга?” соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева